КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1167

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 417 нче карары белән расланган Идарә итүче компанияләрнең һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларының инфраструктурасын үстерү өчен аларга заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идарә итүче компанияләрнең һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларының инфраструктурасын үстерү өчен аларга заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 417 нче карары белән расланган Идарә итүче компанияләрнең һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларының инфраструктурасын үстерү өчен аларга заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян

(фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирү тәртибенә, 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«14. Субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата сәнәгать (индустриаль) паркларының идарә итүче компанияләренә һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларына сәнәгать (индустриаль) паркларының коммуналь һәм юл инфраструктурасы объектларын, биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү өчен бирелгән заемнарның 100 процент бирелгән субсидия күләмендәге суммасы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин